ГЛАВА ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Чехова, д.18, с. Верхний Услон, 422570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ
Чехов ур., 18 нче йорт, Югары ослан авылы, 422570

Тел.: (84379) 2-13-38, факс: (84379) 2-18-39. E-mail: sovet.uslon@tatar.ru, verhniy-uslon.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

_______________ с. Верхний Услон _______________

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы Министрлыгының рөхсәт ителгән төзелешнең иң чик параметрларыннан тайпылуга, капиталь төзелеш объектын реконструкцияләүгә рөхсәт бирү турындагы боерыгы проекты буенча иҗтимагый фикер алышулар билгеләү турында

Татарстан Республикасы Югары Ослан районында яшәүчеләрнең уңай тормыш шартлары, җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары хокуклары ияләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2013нче елның 6нчы октябреннән 131-ФЗ Федераль закон, «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районында җәмәгать фикер алышуларын оештыру һәм үткәрү турындагы Нигезләмә нигезендә, гр. Мишина О.Ю.мөрәҗәгатен карап

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы, Югары Ослан муниципаль районы, Югары Ослан авыл җирлеге, Югары Ослан авылы, Печән складлары урамы адресы буенча урнашкан, 16:15:050118:410 кадастр номерлы, 891 кв. м мәйданлы җир кишәрлеген капиталь төзелеш объектларын төзүнең рөхсәт ителгән чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирү турында Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Югары Ослан авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең индивидуаль торак төзелеше (Ж1) зонасында "шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен" җир кишәрлеген капиталь төзү объектларын төзүнең рөхсәт ителгән чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирү турында Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы боерыгы проекты буенча иҗтимагый фикер алышулар билгеләргә:

- җир кишәрлеге чикләреннән 2 нче ноктадан алып 3 нче ноктага кадәр минималь чигенүләрне киметү өлешендә - 1,6 м га кадәр (1нче кушымта).

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

2.1. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән проектны карау буенча иҗтимагый фикер алышуларны оештыручы Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге (алга таба - җәмәгать фикер алышуларын оештыручы).

2.2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән проектны карау буенча 2024 елның 18 декабреннән 2025 елның 06 гыйнварына кадәрге чорда Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль Законда, «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставында билгеләнгән тәртип, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районында җәмәгать фикер алышуларын оештыру һәм уздыру турында нигезләмә  нигезендә иҗтимагый фикер алышулар үткәрергә.

2.3. Проект экспозициясен үткәрү урыны - Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Советы бинасы,2024 елның 18 декабреннән 2025 елның 06 гыйнварына  кадәр эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайты. Тәкъдимнәр, искәрмәләр 2024 елның 18 декабреннән 2025 елның 06 гыйнварына кадәр сишәмбе һәм пәнҗешәмбе 14.00 сәгатьтән 15.00 сәгатькә кадәр язма рәвештә һәм (яисә) Alina.Sagdeeva@tatar.ru электрон почтасы аша кабул ителә.

3.Җәмәгать фикер алышуларын оештыручыга әлеге рөхсәт соралган җир кишәрлеге белән уртак чикләре булган җир кишәрлекләренең һәм капиталь төзелеш объектларының хокук ияләренә җиткерү өчен проект буенча җәмәгать фикер алышулары үткәрелү турында Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Югары Ослан авыл җирлеге Башкарма комитетына хәбәр җибәрергә.

4. Мөрәҗәгать итүче гр. Мишина О.Ю. иҗтимагый фикер алышуларны оештыруны техник яктан тәэмин итәргә, шул исәптән экспозиция үткәргәндә дә.

5. Иҗтимагый фикер алышуларны оештыручыга:

5.1. Әлеге карарның 1нче пунктында күрсәтелгән проектны карау буенча иҗтимагый фикер алышуларны үткәрүне тәэмин итәргә.

5.2. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Советы бинасында һәм Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында «Архитектура һәм шәһәр төзелеше» кушымтасында төзелгән мәгълүмати стендта проектлар буенча иҗтимагый фикер алышулар башлануы турында хәбәр урнаштырырга.

5.3. Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, «Архитектура һәм шәһәр төзелеше» кушымтасында бәян итәргә:

- Татарстан Республикасы, Югары Ослан муниципаль районы, Югары Ослан авыл җирлеге, Югары Ослан авылы, Печән складлары урамы адресы буенча урнашкан, 16:15:050118:410 кадастр номерлы, 891 кв. м мәйданлы җир кишәрлеген капиталь төзелеш объектларын төзүнең рөхсәт ителгән чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирү турында Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Югары Ослан авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең

җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең индивидуаль торак төзелеше (Ж1) зонасында "шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен" җир кишәрлеген капиталь төзү объектларын төзүнең рөхсәт ителгән чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирү турында Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы боерыгы проектын:

- җир кишәрлеге чикләреннән 2 нче ноктадан алып 3 нче ноктага кадәр минималь чигенүләрне киметү өлешендә - 1,6 м га кадәр (1нче кушымта).

5.4. Экспозицияләрне Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Советы бинасында, әлеге карарның 2024 елның 18 декабреннән 2025 елның 06 гыйнварына  кадәр, эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр, шулай ук Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында оештырырга.

5.5. Иҗтимагый фикер алышулар тәмамлангач, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында иҗтимагый фикер алышулар нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләргә һәм урнаштырырга.

6. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы Е.А.Варакин